# ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕР АЛЫШУЛАР БАШЛАНУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Иске Үтәмеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Иске Үтәмеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итә (алга таба – Проект).

1. Проектта Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Иске Үтәмеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау каралган һәм ул гавами тыңлауларда каралырга тиеш.

2. Гавами тыңлаулар уздыру тәртибе Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге №80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү вакыты гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр басылып чыккан көннән алып җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр - 21 көн.

3. Проект экспозициясе Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Тематик бүлекләр/Гавами тыңлаулар» бүлегендә урнаштырылган.

4. Проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү 20.12.2024 елдан 08.01.2025 елга кадәр түбәндәге адрес буенча: Иске Үтәмеш авылы, М.Җәлил урамы, 52 йорт 08.00 дән 17.00 гә кадәр, Чирмешән авылы, Совет урамы, 32 йорт 08.00 дән 17.00 гә кадәр.

Проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин (08.01.2025 елга кадәр):

1) түбәндәге адрес буенча: Иске Үтәмеш авылы, М.Җәлил урамы, 52 йорт Иске Үтәмеш авыл җирлеге Башкарма комитеты; Чирмешән авылы, Совет урамы, 32 йорт Район Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

2) «Гавами тыңлаулар/Иҗтимагый фикер алышулар» тамгасы белән электрон почтага: Elvira.Ziganshina@tatar.ru

Татарстан Республикасы<br>
Чирмешән муниципаль районы<br>
«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»<br>
муниципаль берәмлегенең<br>
җирдән файдалану һәм төзелеш<br>
кагыйдәләре проектын әзерләү<br>
буенча комиссия